**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«06» 02 2024 ел          Яр Чаллы ш.          № 341

«ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе» тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында» 2023 елның 12 октябендәге 3437 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2023 елның 12 октяберендәге 3437 номерлы карары белән расланган ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Князево урта белем бирү мәктәбе » муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе          А.Р. Хәбибуллин

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «06» 02 347 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 январеннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Мәктәпкә әзерләнү» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Мәктәп алдыннан» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Яшь риторик» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районының
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү
Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры _______________ О.А. Дубей

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә
хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ
җитәкчесе урынбасары _______________ Р.Р. Йосыпова

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Князево урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Мәктәпкә әзерләнү»**- күзәтүләр уткәрү, чагыштыру, объектның күрсәтелгән һәм яңа үзлекләрен, аның мөһим һәм әһәмиятсез характеристикаларын билгеләү, үзлекнең чагыштырмалылыгын аңлау, төп нәтиҗәләр ясау күнекмәләрен үстерүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (8 кеше).

Бинаның мәйданы: 50,40 кв.м.

2. **«Мәктәп алдыннан»**- бәйләнешле сөйләм, фонетик ишетү, иҗади фикерләү, хәрәкәтләрнең координациясе һәм вак моторикасы, язучы кулның хәрәкәт аппараты мускуллары, күрү һәм хәрәкәт факторлары функцияләрен үтәүче төрле эшчәнлек төрләре аша баланың төрле яклы үсешенә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (8 кеше).

Бинаның мәйданы: 50,40 кв.м.

3. **«Яшь риторик»** - укучыларны сөйләм тәртибе культурасы белән таныштыруга, театраль эшчәнлек элементларын куллану нигезендә аларның сөйләмен камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 10 яшьтән алып 15 яшькә кадәрге балаларга күрсәтелә (10 кеше).

Бинаның мәйданы: 28 кв.м.

ТР Тукай муниципаль районының
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү
Князево урта гомуми белем бирү
мәктәбе» МБГББУ директоры _______________ О.А. Дубей